

ИДРИС ТУКТАР

# ТАНЫШ ТУРГАЙЛАР

9 тиен

© Татарстан китап нәшрияты, 1973

**Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга**

Туктаров Идрис Ильясович

**ЗНАКОМЫЕ ЖАВОРОНКИ**

Рассказы

(на татарском языке)

Редакторы С. Сибгатуллина

Художникгы С. Кульбака

Художество редакторы Г. Трифонов

Техник редакторы С. Әхмәтҗанова

Корректоры Д. Миңнуллина

Производствога бирелде 25/X-1973 ел. Басарга кул куелды 1/VI-1973 ел. Типография кәгазе № 1, $70 \times 90^1/_{16}$. Учетн.-изд. табагы 2,02. Якынча басма табагы 2,34. Тираж 8000. Заказ Г-704. Бәясе 9 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. Казан, Бауман ур., 19.

Татарское книжное издательство. Казань, Баумана, 19.

ТАССР Министрлар Советының Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинаты. Казан, Бауман ур., 19.

ИДРИС ТУКТАР

# ТАНЫШ ТУРГАЙЛАР



С(Тат)2
Т 73

$\frac{\text{Т 0762—153}}{\text{М 132(03)—73}}$ 150—73


## АБЫЕМ БҮРЕГЕ

### I

Абыем эшеннән бик арып кайткан иде. Ул, эчке күлмәген салып, биленә кадәр юынып алгач:

— Энекәш, капканы гына ябып кер әле, — диде.

— Караңгы төшкән ич инде, абыем, куркам, — дидем.



БИБЛИОТЕКА
ТАТКНИГОИЗДАТА
Инв. № 7825

— Курыксаң, минем бүрекне ки, — диде дә капканы ябарга чыгып та китте.

Эх, абыем шикелле батыр йөрәкле булсаң иде! Минем абыем караңгы дими, яшенле яңгыр ява дими, эт дими, ата каз дими, — бернәрсәдән дә курыкмый. Солдатта булып кайтканнан бирле, ул миңа: „Минем бүрек күпне күргән. Бүрегем исән булса, мин куркуның нәрсә икәнен дә белмәячәкмен. Син курыксаң, минем бүрекне генә ки“, — дигән сүзләрне әйтә дә тора, әйтә дә тора...

— Капка ябылды, хәзер йокларга ятсак та була, — диде абыем.

— Бу юлы син бүрегеңне кими чыктың ич, анда да курыкмадың, — дидем мин.

Ә ул:

— Аның сере бар, энекәш, — дип, бүрегенең серен дә аңлатып бирде.

## II

Җил сызгыра-сызгыра, ыжгыра-ыжгыра, котыра-котыра яңгырлы-яшенле дөм-караңгы төнне алып килде. Абыемның бүреген басып торып кидем дә әкрен-әкрен генә атлап тышка чыктым, капканы шартлатып яптым да өйгә чаптым да кердем!

— Сизденме инде минем бүрекнең кыюлыгын? — диде абыем.

— Сиздем, — дидем.

— Аз гына булса да курыкмадыңмы? — диде абыем.

— Аз гына курыктым, аз гына курыкмадым, — дидем.


— Син минем бүрекне иртәгә көндез тагын киеп, урамга чыгып кара әле, барлык ата казлар синнән качарлар, күр дә тор, — диде абыем.

## III

Икенче көнне мин абыем бүреген басып торып кидем дә, урамга әкрен генә чыктым һәм усал соры ата казга таба юнәлдем. Усал ата каз башта миңа кимсеткән кыяфәт белән карап



кына алды. Мин, абыем бүреген тагы да басыбрак киеп, ата казга каршы җәһәтрәк атладым. Ата каз, гаҗәпсенебрәк калса да: „Кара, кирәгеңне алырсың!“ — дигән кебек, башын чөйде, ысылдап, муенын озынайткач, канатларын салындыра төште дә



миңа каршы йөгерде. Я мин чигенәм, я ул чигенә, я мин чигенәм! — дип уйлап бер-беребезгә каршы барганда, ата каз, кинәт туктап калып, муенын кыскартты, кыскартуы белән, читкә борылып, тәпиләрен лапылдата-лапылдата, чабып та китте! Мескен кыяфәткә кереп, юашланып калган соры, усал ата казга мин:

— Әһә, хәзер шулаймы? — дидем. — Син элек безне куган саен: „Ыңгый-мыңгый!.. Га-га-га!“ — дип, койрыгыңны дерелдәтә-дерелдәтә, ана казың алдында мактана торган идең! Абыем бүреге белән шаярырга ярамаганны аңладыңмы инде хәзер? Күпне күргән бүрек шул ул! Аның сере дә бар әле... — Шулай гына дигән идем, малайлар белән кызларны күреп алдым. Алар, минем батырлыгыма сокланып, усал ата казны әрләвемә исләре китеп, тыңлап торалар икән. Мин абыем бүреген кыңгыр салдым да:

— Кайда тагын усал ата казлар бар? Китерегез аларны миңа! — дип, әкрен генә атлап өебезгә кереп киттем.

## IV

Абыем, усал ата казны җиңүемне белгәч:

— Я энекәш, бу юлы да азрак курыктыңмы? — диде.

— Бу юлы, абыем, азрак курыктым, күбрәк курыкмадым, — дидем.

Абыем, күзләре белән генә елмаеп, тәрәзәне ачып җибәрде.

— Әнә, кара әле, малайлар белән кызлар, абыйларының бүрекләрен киеп, безгә таба йөгерәләр түгелме? — диде ул.

Җанлы гөмбәләргә охшап калган малайлар белән кызлар, әлеге усал ата казга әйләнеп карый-карый, безнең тәрәзә төбенә килеп туктадылар. Кечкенә Йолдыз, күзләренә үк төшкән колаклы бүреген артка этәреп:

— Усал ата каздан курыкмаска теләп, без дә абыйларыбызның бүрекләрен киеп чыккан идек, ә үзебез куркабыз. Нигә алай икән? — диде.


Абыем елмаеп җавап бирде:

— Батырлыкның сере — курыкмауда ул, егетләр, кызлар!

## ӨЛГЕР

Өлгер белән без икәү дус. Хәер, Өлгер белән бик күп, бик күп кешеләр дуслашканнар. Тик менә кайбер балалар гына Өлгер белән очрашырга өлгермәгәннәр әле.


Беркөн мин Өлгерләрдә кунакта булдым. Өлгер белән аның әнкәсе шулай сөйләшеп алдылар:



— Балам, су алып кайтчы. Утын да кертәсе бар икән.
— Су да алып кайттым, утын да керттем, әнкәй.
— Бик хуп, балам, күрми дә торам икән. Ә керткән утының кайда соң?
— Утынны мин, әнкәй, аунап ятмасын дип, мичкә тутырып та куйдым инде.
— Минем эшләрем кимегән икән. Кая, алай булгач, пальто төймәңне нygытып алыйм, төшеп калмасын.
— Мин ул төймәне үзем ныгыттым инде, әнкәй, бер кечкенә генә ямау да салдым.
— Меңә рәхмәт, балам! Әмма һаман шулай булса, мин үзем эштән бөтенләй бизмәмме икән соң? — дип елмайды әнкәсе.
— Син, әнкәй, юрамалый сөйли башладың: эшкә өйрәткән кеше эштән бизә аламыни?
Өлгернең әнкәсе, шатланып, кулына китап алып утырды. Өлгер белән без икәү шахмат фигураларын тезеп алдык... Сигезенче йөрүемнән отылдым да куйдым! Мин, гаҗәпсенеп, бераз дәшми торгач:
— Тукта әле, Өлгер, болай яхшы итеп уйнарга син кайчан гына өлгердең әле? — дидем.
Өлгер җитди генә җавап кайтарды:
— Өлгер булганга күрә өлгердем.
Өлгер белән без икәү дус дигән идемме әле мин сезгә? Дөрес. Шулай булгач, миңа да бөтен эштә Өлгер артыннан өлгерергә кирәк. Өлгернең төс-буйлары белән гадәтләре турында сөйләп тормыйм инде: Өлгер һәр көн сезнең үз арагызда йөри ул.

## АВЫРАЯК

Авыраяк озак йоклады. Ахырда уяттылар үзен. Иснәнде. Киерелде. Тәрәзә аша тышка карады. Тышта тәрәзә каршында боз каткан иде.
Авыраяк:



— Әнкәй, минем конькиларым кайда икән? — диде.
Әнкәсе белән бергә конькиларны эзләп таптылар.
— Әнкәй, минем конькиларны бәйләш әле.
Әнкәсе конькиларны бәйләште.
— Әнкәй, минем пальтом кайда?
Авыраякның пальтосы үз урынына эленмәгән иде.
— Әнкәй, әнкәй! Минем бүрегем кайда сон?
Авыраякның бүреге су кисмәге артыннан табылды.
— Әнкәй, әнкәй... Баядан бирле әнкәй дим! Минем бияләйләрем кайда икән инде?..
Бияләйләрнең берсе кровать астында, икенчесе кушетка астында яткан. Әнкәсе аларны кисәү таягы белән өстерәп чыгарды.
Авыраяк авыраеп кына ишек алдына чыкса... әлеге боз эрегән дә беткән!
Авыраяк авыраеп өйгә керде:
— Әнкәй, конькиларымны чишеш.
Конькилар чишелде.
— Әнкәй, пальтомны салыш.
Пальто салынды.
— Әнкәй, әнкәй, бүрегемне элеп куй.
Бүрек эленде.
— Әнкәй, әнкәй... Баядан бирле әнкәй дим! Бияләйләремне дә алып куй.
Бияләйләр дә алып куелды.
Авыраяк авыраеп тышка караса, әлеге эрегән боз... янадан каткан!
Авыраяк авыраеп кына уйлап алды:
— Мин бу кышны коньки шуа алырмынмы икән? Әллә яңа кышны көтимме икән?..

## ТАНЫШ ТУРГАЙЛАР

Бу хәл былтыр яз укыганда булды.
Авылыбыз өстеннән канатчыкларын кызу-кызу җилфердәтеп, һавада тирбәлә-тирбәлә, бер пар тургай сайрап үтте. Тургай тавышын беренче рәт ишеткәндәй, җаным-тәнем белән кинәнеп-рәхәтләнеп, мин карап калдым.



Очып-очынып, биектән биеккә күтәрелеп күздән югалсалар да, аларның дәртле авазлары көчәя генә барган сыман тоелды.

Туктагыз әле! Сайраулары һавада эри, югала, бетә, ишетелер-ишетелмәс кенә булып кала инде дип уйлап та өлгермәдем, як-яклардан тагын уннарча, йөзләрчә пар тургайлар күтәрелде. Сайраша-сайраша түгәрәк хор булып оештылар да, кыр-болыннарны өзлексез яңгыратып, юмарт концертларын дәвам иттеләр.

Тургайлар сайравы әле кыңгырау, әле чишмә тавышын хәтерләтә иде.

Нинди матур! Нинди соклангыч авазлар!

Ару-талуны белмәгән бу оста җырчыларны мин бөтен йөрәгем белән ярата башладым...

## ӘРДӘНӘ

Вил белән Нил иртүк балык тотарга китмәкчеләр иде. Ләкин әткәләре:

— Сез башта кичә кискән утыннарны өеп алыгыз әле, — диде.

— Хәзер... Була ул, әткәй, — дип, Нил өйдән чыгып та сызды.



Ялгызы гына калган Вил, көрсенеп:

— Нилның „хәзер“ белән „була“лары гел үзе өчен генә: берәр төрле йомыш куштыларммы, шылу ягын гына кайгырта,— диде дә утын өяргә керешге.

Әрдәнә тигез, тыгыз һәм матур булып чыкты. Вил, үз эшенә үзе сокланып карап торды да, шатлана-шатлана, кармак сабын алып, балыкка китте.

Өйләреннән чыгып сызучылар, сыкрана-сыкрана булса да, бер әйләнеп кайталар алар. Нил да шулай кайтып керде.

— Әткәй күренгәнче... — дип, ул әрдәнә өстен ишеп төшерде дә яңадан өяргә тотынды. Өеп бетерүгә, утыннар, дөбер-шатыр килеп, ишелеп төшмәсенме! Нил: „Берәрсе күзәтеп тормагае тагы“, — дигән сыман карангалап, тырыша-тырыша, эшен янабаштан тәгәлләде. Бу минутта аны бирелеп эшләү нәтиҗәсендә генә туа ала торган күңел рәхәтлеге чорнап алды. Нил, маңгай тирләрен сөртә-сөртә, шул рәхәтлегеннән аерыла алмыйча, бүкән өстенә барып утырды.

Әткәсе кайтып керде.

— Булдырдыгызмы?

— Абый әрдәнәне нинди матур итеп өя белә икән! — дип җавап бирде Нил.

— Ә син үзең кеше эшләгәнгә сокланып, карап кына утырдыңмы?

— Мин дә, абый кебек өя аламмы икән дип... яңадан өйдем... Өйрәнә-өйрәнә... Матурмы?

— Гаҗәп матур!.. Туктале, буең ничек җитте соң синең?

— Буй эшләми, кул эшли, дисең ич син үзең, әткәй...

Әткәсенең елмаеп карап калуына тагын да кәефләнә төшеп, Нил балыкка чыгып чапты.

## БУКЕТ

Ул көнне мин кыр чәчәкләрен арыганчы җыйдым. Бер кочак булды. Көчкә күтәреп кайттым. Урамда миңа Хәмзә очрады.

— Һе! Печән түгел инде бу. Күр дә тор, кәҗәгез авыз итеп тә карамас, — дип көлде ул миннән.



— Аны сиңа кем әйтә әле печән дип? Бүлмәбезне матурлау өчен букет ясыйм мин ул чәчәкләрдән.

— Һи-һиии! Кеше күтәрә алмаслык букетмы?!. Тапкансың эш! — дип тагы көлде Хәмзә...

„Чынлап та, букетым шулай бик ук зур булырмы икәнни? Ай-һай, бу кадәр күп чәчәкләрдән... йөзләп букет чыгар. Ничәне ясыйм икән?“ — дип уйга калдым.

Минем бәхеткә бакчачы Зөфәр бабай килеп чыкты.

— Букетның хикмәте аның зурлыгында түгел, улым. Кая, китер әле чәчәкләреңне. Букетың матур булсын дисәң, чәчәкләрне менә болай тезәргә кирәк, — диде дә ул, бармакларын җитез хәрәкәтләндереп, букет ясарга кереште. — Бер үк төсле эре яки бер үк төсле вак чәчәкләрдән ясалган букетлар карар күзгә алай бик үк ятышлы булмыйлар. Чәчәкләрнең төрлесеннән тезелгән букет кына күңелләрне шатландыра. Әйтик, озын яфраклы яушан чәчәге янына аю көпшәсе килешми, ни өчен дисәң, алар икесе дә зәңгәр, шунлыктан да алар бер-берсеннән алай ук аерылып та тормыйлар. Димәк, бу чәчәкләр арасына аклы-сарылы алабай яки сары чәчбай чәчәкләрен, я булмаса, җете кызыл кәрләч чәчәген урнаштырырга кирәк була. Ак чәчәкләрне теләсә нинди чәчәкләр янына тезәргә ярый... чама белән, билгеле... Әнис янына ала миләүшә, ала миләүшә янына күкчәчәк... янә алсу карлыган, саргылт казаяк, тукранбаш, канәфер чәчәге, сары мәтрүшкә, иң уртага — кыңгырау чәчәк, күгәрчен күзе һәм... китапча әйткәндә һ. б. һ. б., — дип, елмаеп миңа карап алды Зөфәр бабай. — Кыр чәчәкләренең генә дә барлык исемнәрен тиз генә санап бетереп булмас: әйтик, бер Татарстан кырларында, болын, урманнарында гына 1300 гә якын төр чәчәкләр үсә.

Хәзер без Хәмзә белән шунысын яхшы аңладык: букет тезү — чәчәкләр үстерү кебек үк җитди эш икән ул...


Моңа кадәр тәртипсез, йокымсырап яткан чәчәкләрем, букетка тезелгәч, өр-янадан матураеп, як-якларына карашып елмаештылар.

Букетым, кояш нурларының уйнавын, бал кортларының зыңлавын хәтерләтеп, йомшак хуш исләрен бөркеде.

## БОРЫН

Бер малайның борыны башта нәни генә, матур гына була. Дуслары, шундый борынлы малайны мактап:

— Бик әйбәт малай ул, — диләр, — борыны аның күтәрелми дә, төшми дә.



Малай борынын тотып карый, басып карый, тартып карый да, үз борынына үзе сокланып:

Мондый борын барлыгын
Белмәгән идем бер дә!
Миндә икән ул борын,
Кирәк кадерен белергә! —

дип җырлап җибәрүенә... борын күтәрелә дә китә!

Дуслары:

— Абау, моның борыны бигрәк югары күтәрелгән! — диләр.

Малай борынын тотып карый, басып карый, тартып карый, ләкин борынының күтәрелүен сизми. Шуннан соң ул:

— Дусларым мине юри мыскыл итәләр, — дип зур кайгыга бирелүе белән... борыны төшә дә башлый!

Дуслары бу юлы:

— Карагыз әле, малайның борыны төшкән ич! — дип гаҗәпсенәләр.

Малай борынын тотып карый, басып карый, тартып карый, төшкәнен сизми, ләкин ул:

— Борыным сәламәт түгел, ахры, — дип врачка йөгерә.

Врач аның борынын тотып карый, басып карый, тартып карый һәм, борынының бер күтәрелеп, бер төшеп торуын сизеп, малайга ике төрле дару бирә.

— Даруларның берсе, — ди врач, — дусларын сине мактаган саен масайма, икенче дару — юк-бар нәрсәләргә бирелеп, күңеленне төшермә.

Малай врач биргән даруларны көн дә кабул иткәнгә күрә, борыны элекке хәленә кайта — нәни генә, матур гына булып кала.

## ЛИЛИЯНЕҢ БЕР СЕРЕ

Лилия, классташлары белән бергә мәктәптән кайтканда:

— Дусларым, минем сезгә әйтәсе бер серем бар, — дип ычкындырды. — Мин ул серемне беркемгә сиздермичә йөрдем дә йөрдем, йөрдем дә йөрдем...





Б... ЕКА ТАТ... 4825

Өйләренә ашыгучылар, сумкалары белән бәргәләшеп уйнаучылар, тына төшеп, Лилияне сырып алдылар.

— Я-я, сөйләп кара серенне.

— Яңа күлмәк тектеләрме әллә?

— Шигырь я җыр язгансындыр әле...

— Моңа кадәр серемне әйтергә генә кыймый йөрдем мин, — дип, Лилия туктап иркен тын алды.

— Алай булгач, сөйләмә, кирәкми...

— Малайларның шул булыр инде аларның! Сөйлә әйдә, Лилия, әйт серенне, аларга карама, — диештеләр кызлар, сабырсызланып.

— Мин ул сернең сер икәнен белми дә идем әле, әнием әйтмәсә... Синең сереңсерләр сере ди әни. Ничек кенә итеп төшендерим икән инде мин аны сезгә? Хәзер... — Лилия һич көтмәгәндә сумкасын бер кызга тоттырды да йөгереп тә китте. Ана башкалар да иярде.

Баткакка батып чыга алмыйча торган кызчык, янына Лилия килеп җиткәч:

— Мине баткак батылды... Кука-ам! — дип елап җибәрде.

Лилия аны күтәреп алып коры җиргә бастырды да юата-юата җитәкләп өйләренә таба алып китте. Үзе артыннан ияргән классташларына таба борылып:

— Серем шул инде менә... Тагы да яхшырак аңларга теләсәгез, — ярдәм кирәк һәр җирдә ярдәм итегез, — диде.

## ЯЛКАУ ӨЧЕН БОТКА СУЫНГАН

Җиннәребезне сызганып, без эшкә киттек.
Кашык кадәр генә көрәгенә таянган Ялкау очрады.
— Болай ашыгып кая барасыз? — дип сорады ул бездән.
— Эшкә барабыз, — дидек.



— Мин дә сезнең белән барыйммы, әллә ботка пешкәнен генә көтимме? — диде Ялкау.

— Төш җиткәнче, ботка пешкәнче эшләп алыйк, син дә бездән калышма, — дидек Ялкауга.

— Сез эшкә барып җитеп, әйләнеп кайтып та өлгермәссез, мин дә сезнең артыгыздан куып җитәрмен, — дип, Ялкау баскан урынында йокымсырап калды.

Эшләдек. Арыдык. Ботка ашарга дип кайтканда, көрәк кадәр зур кашыгын күтәреп, Ялкау тагын очрады.

— Ботка суынмас борын мин дә ашыктым, — диде Ялкау.

— Ялкау өчен ботка күптән суынган, — дип, без ботканы үзебез генә ашадык.

## ИГЕЗӘКЛӘР

Игезәкләр — Рәшит белән Рәшидәгә бишәр яшь тулгач, аларның тормышларында тагы да гаҗәбрәк вакыйгалар була башлады. Менә бүген ит турагандa әнкәләре Рәшиткә бер телем ит каптырды, ә Рәшидәгә сөяк тоттырды. Әнкәләренең:



— Ә сина, улым, сөякне иртәгә бирермен, — диюен Рәшит шунда ук онытты. Ул, эленеп торган көянтәне аяк очларына басып үрелеп алды да, Рәшидә янына килеп:

— Рәшидә нәнием, мә сина тәти көянтә, бир мина сөягенне, — диде.

— Көянтәне кимермиләр, анын белән су китерәләр, беләсен килсә, — диде дә Рәшидә сөяген артына яшерде.

— Сөягенне кимерә дә белмисен әле син... теге башыннан кимер, — диде Рәшит.

Рәшидә, сөяген әйләндергәләп:

— Кайсы башыннан? — дип сорады.

— Кая, күрсәтим үзем...

Рәшидә сөяген Рәшиткә сузды.

— Менә бу... башыннан, менә... болай, — ди-ди Рәшит кимереп туйгач, итсез сөякне Рәшидәгә кире бирде. — Белденме инде?..

Рәшидә, иреннәрен турсайтып, гаҗәпләнүеннән елавын да онытты...

Икенче көнне әниләре тагын ит турады. Рәшит:

— Әнкәй, иртәгә дигән сүз кайчан була ул? — диде.

Әнкәләре, елмаеп:

— Менә кайчан була, — дип, улынын кулына сөяк тоттырды. — Утырып кимер, улым.

Рәшит, сөягенә өрә-өрә, өстәл артына утырганда, Рәшидә:

— Кая, күрсәтим үзем, теге башыннан кимер, — диде.

— Мин аны син өйрәтмәсән дә бик яхшы беләм, — дип җавап бирде Рәшит эре генә.

— Ә менә син лобзик дип әйтә белмисен.

— Ашаганда сөйләшергә ярамый... Лобздик.

— Дөрес әйтмәден. Яле, тагын бер әйтеп кара: лоб-зик, диген.

— Лоб-здик.

— Здик түгел, зик.

— Зик-лоб... Моны да белмәсән!

— Зик-лоб түгел, лобзик инде! Шуны да әйтә белмисен.

— Лоб-зик.

— Менә бу юлы дөрес әйттен. Өйрәткән өчен сөягенне мина бир. Мин дә өйрәнгәндә сөягемне сина биреп тордым ич.

Рәшит, сөягенә бер-ике кат мөлдерәп карап алды да, аны Рәшидәгә сузды: нишләмәк кирәк, туры сүзгә җавап юк.

## СЫЕРЧЫК БАЛАСЫ

Сыерчык баласы оясыннан җиргә егылып төште. Анын хәсрәт утында янган әнкәсе, авызындагы җимен ташлап:

— Чөтеррр-җөтеррр! — дип кабатлый-кабатлый, нәнис тирәсендә бөтерелеп оча башлады.



Шул арада берничә чыпчык җыелып килеп, хәлнең мөшкел икәнен башка кошчыкларга да аңлатырга тырыштылар:

— Җөк-җөк! Җөк-җөк!..

Һич көтмәгәндә бер усал мәче килеп чыгып, сыерчык баласына менә хәзер ташлана, менә хәзер аны һәлак итә дигәндә генә, бер абый:

— Мин сине... — дип мәчене куып җибәрде дә, сыерчык баласын иелеп кулына алды. Ул арада бер-бер артлы балалар да йөгерешеп килеп җиттеләр. Абый кеше бер учындагы кошчыкка, бер балаларның елтыр-елтыр итеп торган күзләренә карап елмайды. Балалар, кинәт бер-берсен бүлә-бүлә, шаулашырга тотындылар:

— Абый, сыерчык баласын безгә бирегез...

— Әйе шул!

— Без аны үзебез үстерербез... ашатырбыз.

— Мәчедәнме?

— Бер дә алай түгел, мәчеләрне якын да җибәрмәбез...

— Абый, сез аны башта очыртып карагыз әле...

— Әйе шул! Бәлки, ул яралыдыр, бөтенләй очалмас хәлдә калгандыр.

Абый кеше, кулын чак кына күтәрә төшеп, учын ачкан иде, хәйләкәр малай кошчыкны эләктереп, йөгереп тә китте.

— Очты-очты... сыерчык баласы очты! — диешеп, көлешә-көлешә башка балалар да теге малай артыннан чаптылар.

Абый кеше алар артыннан елмаеп карап калды.

## ТӘРӘЗӘМӘ ТӨШКӘН КОЯШ НУРЛАРЫ

Куркаклыгың турында кычкырып әйтү өчен генә дә батырлык кирәк.

Тауга карап тау булып булмаса да, кешегә карап кеше булып була.

Мин, дип басым ясадыңмы, басылдың калдың!



Яшьлектә бик аз белүенне бик аз beләсең, картлыкта бик аз белүенне бик күп беләсең.

Шырпым бар димә, утым бар диген, даным бар димә, эшем бар диген.

Ялкауга кашык кына җиңел.

Шаяртып әйткәннең чынын үзең аңла.

Мин мактанмыйм, диденме, син мактандың да инде!

Батыр булу өчен курыкмаска гына кирәк.

Алга бармаган да тик тормый — артка чигенә.

Начарлык артыннан кумасаң, яхшылык артыңнан калмас.

Үзе юкның күзе юк булса да, колагы аның була.

Үз кайгыңны үзең кимер, кеше кайгысы да кимер.

Әрәмтамакка буш табак та әрәм.

Кеше эшләре, ат тешләре, солдат батырлыгы, чәчәк матурлыгы белән мактана.

Егет була алмаган — ир була алмас, ир була алмаган — кеше була алмас.

Игелек күрсәтмәгән — игелек күрмәс.

Ашарга ашыкма — төелерсең, эшләргә ашык — сөенерсең.

Кешеләр өчен бер дә борчылмаган кешеләр — кешеләрнең борчыган кешеләр.

Тиен — сумны, минут сәгатьне саклый.

Батырлыкта матурлык.

Күңеленә көя төшкән.

Чын матурлыкны аңлау өчен күңел сафлыгы кирәк.

„Тик торуым алтыннан да кадерле“, — дигән сүзләрен әрәмтамак фәкать ашаганда гына оныта.

Эшеңне көн дә үлчәүгә сал.

## АК МАҢГАЙ БЕЛӘН АЛТЫН КОЙРЫК

*(Әкият)*

Бервакыт төлкеләр үз тормышларыннан зарланырга тоты[...] дылар.

— Бар иде рәхәт яшәгән чаклар! Иртәнге ашка тавы[...] көндезге ашка үрдәк, кичке ашка әтәч алып кайтып, туйганч[...] ашый торган идек.



— Әйтерең бармы!
— Хәзер инде ул көннәр сагынып сөйләргә генә калды.
— Каян гына килеп чыкты шул Ак Маңгай дигән дошманы! — диештеләр төлкеләр.

Төлкеләр арасында хәйләкәрлеге белән дан тоткан Алтын Койрык та шунда иде. Ул җем-җем итеп торган мәһабәт койрыгын бер сузып, бер күтәреп:

— Сез төлкеләр түгел, көлкеләр! — диде. — Ак Маңгай кебек этләргә бирешкән төлкеләрнең исемнәре корысын! Сез минә миннән үрнәк алыгыз. Алтын койрыгым белән ант итеп әйтәм: мин ул көчекне бүген үк куе урманда адаштырып һәлак итмәсәм, шушы койрыгым минеке булмасын...

Алтын Койрык сүзен очларга өлгермәде, һич көтмәгәндә Ак Маңгай килеп чыкты. Төлкеләр күз ачып йомганчы качып та беттеләр. Алтын Койрык урман эченә атылды. Ак Маңгай аны куа китте. Алтын Койрык, койрыгын уңга-сулга, уңга-сулга сала-сала, чапты да чапты. Ак Маңгай аңардан калышмады. Куа торгач, төлкенең ялтырап торган йонлач койрыгын эләктереп өзеп тә алды! Төлке үзе көчкә качып котылды.

Төлкеләр, икенче көнне иртүк тагын җыелышып, кайгырышып ятканда, кичәге Алтын Койрык, хәзер инде Өзек Койрык, килеп җитте.


— Койрыксыз чабуы җиңелрәк тә икән әле. Ак Маңгайдан котылыр өчен моннан соң сезнең барыгызга да койрыкларыгызны кисәргә кирәк, — диде ул.

## ЛӘБИБ БЕЛӘН ХӘБИБ

*(Әкият)*

Ләбиб белән Хәбиб турында сөйләмәкче идем мин сезгә. Ләкин миңа кадәр алар үзләре сөйли башлады:

— Хәбиб, син болай карауга бик әйбәт малай, әмма тегелэй карауга, иллә дә ялкау! — диде Ләбиб. — 4—5 билгеләре синең төшләреңә дә керми торгандыр: көчкә сөйрәлеп барасың



— Нишләмәк кирәк инде, холкың шундый булгач! — ди әйтеп куйды Хәбиб, иренеп кенә. — Ялкаулыгымны мин ташлар идем дә, ул үзе мине ташламый шул.

— Бигрәк әллә нинди син, Хәбиб! Кеше синең белән чынлап сөйләшә... Ә син?..

— Чынлап дисеңме? Алай булгач, әйдә холыкларыбызны алмашыйк. Син миңа үзеңнең тырышлыгыңны бир. Ә мин сиңа үземнең ялкаулыгымны бирим. Ник уйга калдың? Моңа хәтле без синең белән әйберләребезне генә алмаша идек, ә хәзер холыкларыбызны да алмашып торыйк.

— Чынлап та, Хәбиб! Әйдә, бер кызык булсын әле! Бу чирек беткәнчегә кадәр син Ләбиб бул, ә мин Хәбиб булыйм.

Шулай итеп... күзләр ачылып йомылуга... Ләбиб Хәбибкә әйләнде калды! Берәр кеше Ләбибне чакырса, Хәбиб: „Ә?“ — ди, Хәбибне чакырсалар, Ләбиб: „Ә?“ — ди.

Икенче көнне укытучы Ләбибне такта янына чакыргач, ялт итеп Хәбиб чыгып басты. Класстагылар бу хәлгә гаҗәпсенеп, тынсыз калдылар. Укытучы үзе дә, Хәбибне беренче күргәндәй:

— Бу юлы син җавап бирергә булдыңмыни, Хәбиб? Алай булгач, бик әйбәт! — диде һәм арттагы парталарның берсендә куян кебек посып утырган Ләбибкә күз төшереп алды: „Тагын ни булды икән инде бу ике дуска? Хәбиб әйтү белән чыгып басты, ә Ләбибе бөтенләй күренмәскә тырышып иелеп утыра“.

Өченче дәрестә Хәбиб урынына Ләбиб торып басты. Укытучының бер генә соравына да җавап бирә алмады.

— Ләбиб, сиңа ни булды? Бу юлы Хәбибтән үрнәк алырга кирәк әнә. Күрдеңме, ул ничек хәзерләнеп килгән, ә син... Авырмый торгансыңдыр ич?

— Юк...

— Соң шулай булгач?

Ләбиб, нәкъ элекке Хәбиб кебек, укытучының бу соравын да җавапсыз калдыргач, аның урынына Хәбиб җавап бирде:


— Без алмаштык.

— Нәрсә алмаштыгыз? Аңлатып сөйлә!

— Без Ләбиб белән холыкларыбызны алмаштык. Ул мин булды, мин ул булдым. Нәрсә булыр икән дип.

Бу сүздән бөтен класс шаркылдап көлде. Ләбибкә дә җан керде:

— Әйе шул! Ләкин мин Хәбибнең ялкаулыгын җиңәрмен дип уйлаган идем. Хәбиб минем үз холкымны кире үземә кайтарып бирсен! — диде.



Мона кадәр дәрес саен: „Сорамасалар гына ярар иде!“ — дип „укып йөргән“ Хәбиб атна-ун көн үтүгә иң алдынгы укучыга әйләнде.

Ләбиб өчен дөньяның кызыгы кими, Хәбиб өчен арта торды.

Башкалар аның турында „Кояш көлми дә, елмаймый да“, — ди башладылар.

Хәбиб тә: „Минем ялкаулык дустым өчен күтәрә алмаслык авыр йөккә әйләнде. Ялкаулык беләи куркаклыктан да начар нәрсә юк икән. Аңа ничек ярдәм итәргә инде“, — дип уйлый башлады. Әмма аның һич тә элекке Хәбибкә әйләнәсе килми иде. Хәбиб тырышлыкның ни икәненә тәмам төшенгән һәм, үзе әйтмешли, аны һичкайчан да кулыннан ычкындырмаска тырыша. Әмма дус малаена да ашыгыч ярдәм күрсәтергә кирәк. Ул монысын да белә иде.

Ахыр килеп, берле-икеле билгеләр көннән-көн күбәя башлагач, „йокы мичкәсе“ дигән кушамат та тагылгач, Ләбиб бу хәлдән тәмам туйды. Көннәрнең берендә ул, капка төбендә кызынып утырган җиреннән:

— Хәбиб, әйдә холыкларыбызны кире алмашыйк, — дип кычкырды.

— Һе! Алмашмый гына тор әле, яме! Яманны яхшыга алмашулар күңелле, әмма яхшыны яманга алмашулары бер дә рәхәт түгел, — дип җавап кайтарды тегесе. Ә үзенең Ләбибне кызганудан елыйсы килә, үз-үзе белән тартыша, нишләргә белми иде.

— Чирек үтте... Кеше булсаң, сүзеңдә торырга кирәк.

— Дөресен әйткәндә, Ләбиб, синең тырышлыгыңнан файдалану минем үземә дә бик үк ансат булмады.

— Ә миңа синең ялкаулыгыңны күтәреп, йөз кызартып йөрүләре бик ансат булды дисеңме әллә?

— Тукта, ачуланма әле син, Ләбиб! Бу юлы да берәр җае табылмас микән? Бераз уйлашыйк әле... Әһә, булды гына! Син элекке тырышлыгыңның яртысын кире үзеңә ал. Ә мин үземнең ялкаулыгымның яртысын алыйм, булдымы?

— Булды гына! Безгә күптән шулай эшлисе калган.

Икесенең дә күңеленә рәхәт булып китте. Әкият тә шунда бетте.

ЭЧТӘЛЕК


Абыем бүреге . . . . . . . . . . . 1
Өлгер . . . . . . . . . . . . . 5
Авыраяк . . . . . . . . . . . . 7
Таныш тургайлар . . . . . . . . 9
Әрдәнә . . . . . . . . . . . . . 11
Букет . . . . . . . . . . . . . 13
Борын . . . . . . . . . . . . . 15
Лилиянең бер сере . . . . . . . . 17
Ялкау өчен ботка суынган . . . . 19
Игезәкләр . . . : . . . . . . . 21
Сыерчык баласы . . . . . . . . . 23
Тәрәзәмә төшкән кояш нурлары . . 25
Ак Маңгай белән Алтын Койрык . 27
Ләбиб белән Хәбиб . . . . . . . 29